# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан в части установления ограничения продажи несовершеннолетним отдельных товаров**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 октября 2022 года

**Статья 1**

Внести в Кодекс Республики Татарстан об административных правонарушениях (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I часть), № 9 – 10, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I часть), № 7 (I часть), № 7 (II часть), № 10 (II часть); 2011, № 6 (I часть), № 8 (I часть), № 10 (I часть), № 11 (I часть); 2012, № 1, № 6 (I часть), № 7 (I часть), № 12 (I часть); 2013, № 1, № 2 (I часть), № 6 (II часть), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I часть), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I часть); 2016, № 5, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I), № 55 (часть I), № 85 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 83 (часть I); 2020, № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 77 (часть I); 2022, № 49 (часть I) следующие изменения:

1) главу 2 дополнить статьями 2.19 и 2.20 следующего содержания:

«Статья 2.19. **Несоблюдение ограничения розничной продажи несовершеннолетним безалкогольных тонизирующих напитков, а также вовлечение несовершеннолетних в их потребление**

Несоблюдение ограничения розничной продажи несовершеннолетним безалкогольных тонизирующих напитков, а также вовлечение несовершеннолетних в их потребление –

влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от трех тысяч до пяти тысяч рублей; на должностных лиц – от тридцати тысяч до пятидесяти тысяч рублей; на юридических лиц – от ста тысяч до ста пятидесяти тысяч рублей.

Статья 2.20. **Несоблюдение ограничения розничной продажи несовершеннолетним товаров для личных и бытовых нужд граждан, содержащих сжиженный углеводородный газ, а также вовлечение несовершеннолетних в потребление путем вдыхания сжиженного углеводородного газа**

Несоблюдение ограничения розничной продажи несовершеннолетним товаров для личных и бытовых нужд граждан, содержащих сжиженный углеводородный газ, а также вовлечение несовершеннолетних в потребление путем вдыхания сжиженного углеводородного газа –

влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от трех тысяч до пяти тысяч рублей; на должностных лиц – от тридцати тысяч до пятидесяти тысяч рублей; на юридических лиц – от ста тысяч до ста пятидесяти тысяч рублей.»;

2) в статье 7.1 цифры «2.11 – 2.18» заменить цифрами «2.11 – 2.20»;

3) часть 14 статьи 8.1 после цифр «2.17,» дополнить цифрами «2.19, 2.20,».

**Статья 2**

Внести в статью 1 Закона Республики Татарстан от 30 июля 2010 года № 60-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан государственными полномочиями Республики Татарстан по определению перечня должностных лиц, уполномоченных составлять протоколы об административных правонарушениях» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 7 (II часть); 2013, № 2 (I часть), № 6 (II часть), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 83 (часть I); 2019, № 79 (часть I); 2020, № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 87 (часть I); 2022, № 49 (часть I) изменение, дополнив ее после цифр «2.17,» цифрами «2.19, 2.20,».

**Статья 3**

Внести в Закон Республики Татарстан от 14 октября 2010 года № 71-ЗРТ «О мерах по предупреждению причинения вреда здоровью детей, их физическому, интеллектуальному, психическому, духовному и нравственному развитию в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 10 (II часть); 2011, № 10 (I часть); 2013, № 10; 2015, № 10 (I часть) следующие изменения:

1) статью 1 после слов «(далее – Федеральный закон)» дополнить словами «, Федеральным законом от 21 ноября 2011 года № 323-ФЗ «Об основах охраны здоровья граждан в Российской Федерации»;

2) статью 2 дополнить пунктами 6 и 7 следующего содержания:

«6) безалкогольные тонизирующие напитки – напитки, соответствующие требованиям, установленным Национальным стандартом Российской Федерации ГОСТ Р 52844-2007 «Напитки безалкогольные тонизирующие. Общие технические условия»;

7) товары для личных и бытовых нужд граждан, содержащие сжиженный углеводородный газ, – зажигалки, в которых имеется контейнер со сжиженным углеводородным газом, а также баллоны, содержащие сжиженный углеводородный газ, используемые для работы бытовых приборов, заправки зажигалок.»;

3) дополнить статьями $7^1$ и $7^2$ следующего содержания:

«Статья $7^1$. **Ограничение розничной продажи несовершеннолетним безалкогольных тонизирующих напитков и запрет вовлечения несовершеннолетних в их потребление**

1. Не допускается розничная продажа несовершеннолетним безалкогольных тонизирующих напитков.

2. Запрещается вовлечение несовершеннолетних в потребление безалкогольных тонизирующих напитков путем покупки для них либо передачи им таких напитков, предложения или требования их употребить.

Статья $7^2$. **Ограничение розничной продажи несовершеннолетним товаров для личных и бытовых нужд граждан, содержащих сжиженный углеводородный газ, и запрет вовлечения несовершеннолетних в потребление путем вдыхания сжиженного углеводородного газа**

1. Не допускается розничная продажа несовершеннолетним товаров для личных и бытовых нужд граждан, содержащих сжиженный углеводородный газ.

2. Запрещается вовлечение несовершеннолетних в потребление путем вдыхания сжиженного углеводородного газа путем предложения или требования его употребить.».

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан ____________ Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
02 ноября 2022 года
№ 80-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.19 һәм 2.20 статьялар өстәргә:

«2.19 статья. **Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү**

Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәгән, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп иткән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.

2.20 статья. **Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп итү**

Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләүне үтәмәгән, шулай ук балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп иткән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.18» саннарын «2.11 – 2.20» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.17,» саннарыннан соң «2.19, 2.20,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), аңа «2.17,» саннарыннан соң «2.19, 2.20,» саннарын өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «(алга таба – Федераль закон)» сүзләреннән соң «, «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен өстәргә;

2) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктлар өстәргә:

«6) алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләр – «Алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар» ГОСТ Р 52844-2007 Россия Федерациясе Милли стандартында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган эчемлекләр;

7) гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарлар – сыекландырылган углеводород газ контейнеры булган кабызгычлар, шулай ук көнкүреш җиһазларын эшләтү, кабызгычларга газ салу өчен кулланыла торган сыекландырылган углеводород газы кергән баллоннар.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ һәм $7^2$ статьялар өстәргә:

«$7^1$ статья. **Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сатуны чикләү һәм балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итүне тыю**

1. Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне ваклап сату рөхсәт ителми.

2. Балигъ булмаганнарны алкогольсез тонусны күтәрә торган эчемлекләрне куллануга алар өчен сатып алу яисә аларга мондый эчемлекләрне тапшыру, аларны куллану тәкъдиме яисә таләбе юлы белән җәлеп итү тыела.

$7^2$ статья. **Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сатуны чикләү һәм балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша куллануга җәлеп итүне тыю**

1. Балигъ булмаганнарга гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен сыекландырылган углеводород газы кергән товарларны ваклап сату рөхсәт ителми.

2. Балигъ булмаганнарны сыекландырылган углеводород газын сулау аша аны куллану тәкъдиме яисә таләбе юлы белән җәлеп итү тыела.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК / АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 80-ТРЗ